РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕНЫРТИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422063, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Б.Нырты, ул. М Джалиля, д.13
тел. (84362) 45-2-32

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ НЫРТЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422063, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Нырты авылы, М Җәлил урамы, 13 йорт
тел. (84362) 45-2-32

e-mail: Bnir.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ 24.06.2024

КАРАР №10

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлегенең җирләү өлкәсендәге җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлешенә нигезләнеп, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Усавы нигезендә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Советы Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советына Саба муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге башкарма комитетына кабул иткән очракта:

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

әлеге карарны тормышка ашыруны тәэмин итү максатларында 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында Саба муниципаль районы Советы Карары проектын эшләү һәм бюджет законнары нигезендә карауга тапшыру.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Нырты авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/nirti.

4.Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Олы Нырты авыл җирлеге башлыгы Р.З.Сәфәргалиев